БЕЗНЕҢ ҖАВАП
Алабугада яңа машиналар җитештерә башлыйлар
> 2



МӘҺДИЕВ ЭЗЛӘРЕННӘН
Әдип туган авылын таныр идеме икән?
> 3

ҖИҢҮ ӨЧЕН
Чистайдан Алмаз Гыйматдинов, Луганскига барып, туганына машина тапшырып кайткан
> 3

АКЫЛЛЫ КӨЧ
Башкалада компьютер уеннары белән спортны берләштерделәр
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 176 (28949) | Сишәмбе | 29 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Торак базары

Фатир күп, алучы юк. Торак базарындагы бүгенге вазгыятьне белгечләр кыскача шулай дип бәяли. Базарда тәкъдим зур, әмма халык фатир алырга ашыкмый, ди алар. Күпләрнең моңа мөмкинлеге юк. Кулында бераз акчасы булган кеше исә сабыр итү яклы. Иртәгәсе көнгә ышаныч булмау куркыта. Ел азагына кадәр торак базарыннан ни көтәргә?

Быел торак базары өчен аеруча катлаулы чор булды. Ел башыннан ук сынала башлады ул. Хәтерләсәгез, февраль аенда вазгыять кискен үзгәреп куйгач, Россия Үзәк банкы төп ставканы 20 процентка кадәр арттырды. Бу соңгы еллардагы рекордлы күрсәткеч дип бәяләнде. Моңа кадәр төп ставка 9,5 процент тәшкил итә иде. Төп ставка ике тапкыр арттырылгач, ипотека кредитының минималь ставкасы да 20 процентка кадәр үк җитте. Шуңа бәйле рәвештә Россиядә рәсмиләштерелгән ипотека килешүләре 5 тапкыр (!) кимеде. Үзәк банк ел дәвамында ставканы берничә тапкыр киметте. Бүген ул 7,5 процент тәшкил итә.

Әмма бу да торак базарын әллә ни җанландыра алмады. Риелтор Эльвира Рәхмәтуллина сүзләренә караганда, бүген торак базары торгынлык чоры кичерә.

– Илдә өлешчә мобилизация игълан ителүгә, бер атна эчендә фатирларга сорау 15–20 процентка кимеде. Бу аңлашыла да. Барыбыз да шок хәлендә идек бит. Күпләр мондый шартларда ни эшләргә белмичә югалып калды. Бик күп килешүләр өзелде. Клиентларыбыз арасында, өлешчә мобилизациягә эләгүе аркасында, фатир алуны кичектереп торучылар да шактый булды. Бүген вазгыять акрынлап элеккеге хәленә кайта кебек. Фатир алу-алыштыруны кичектереп торган кешеләр бу мәсьәлә белән яңадан кызыксына башлады. Әмма шулай да фатирларга ихтыяҗ без теләгән дәрәҗәдә түгел әле, – ди белгеч.

Мобилизация торак базарындагы сорауны киметсә дә, фатир бәяләрен үзгәртә алмаган. Әйтик, Казанда фатирларның бер квадрат метры бәясе әле дә уртача 144 мең сумнан төшми. Иске йортлардагы фатирларның бер квадрат метр бәясе исә, ел башыннан бирле 8 процентка артып, бүген уртача 143 мең сум тәшкил итә.

Риелтор сүзләренә караганда, мобилизация башлануга, банклар яңа һәм иске фатирларның икесе өчен дә бирелә торган ипотека кредитларының процентларын арттырып куйган. Әйтик, Саклык банкы белән ВТБ банкында ипотека ставкалары, бер ай эчендә 0,5 процентка артып, 10,4 процентка кадәр җиткән. «Уралсиб» банкында исә ул 1,5 процентка ук арткан. Бүген биредә ипотека кредитын ким дигәндә 12,9 процент белән рәсмиләштерергә мөмкин.

– Банклар моны алардан ипотека алмасыннар өчен махсус эшли кебек. Бүген халыкның матди хәлен күреп торабыз бит. Эшсезлек күрсәткече үсә, мобилизациягә эләгүчеләрнең дә язмышы билгесез, – ди Эльвира Рәхмәтуллина.

Белгеч беренче торагын бүген алыргамы-юкмы дип баш ватучыларга бераз сабыр итәргә киңәш итә. Ә менә булган фатирын сатып, зуррагын алырга теләүчеләргә моның өчен бик кулай вакыт дип саный.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ИРКЕНӘЮ

БЕЛГЕЧЛӘР ХӘЗЕР ФАТИР АЛЫШТЫРУ ӨЧЕН КУЛАЙ ВАКЫТ ДИП САНЫЙ

– Бүген икенчел базарда фатирларны бик отышлы бәядән эләктереп калырга мөмкин. Яңа елга кадәр торак бәяләре тагын да арзанаерга мөмкин. Бүген фатир сатучыларның күбесе хакны 200–500 мең сумга кадәр төшерергә әзер. Мондый хәлнең күптән күзәтелгәне юк иде инде, – ди белгеч.

Соңгы берничә ел эчендә Татарстанда торак бәяләре 50 процентка диярлек арткан. Халыкның керемнәре исә үзгәрешсез кала бирә. Татарстанның Риелторлар гильдиясе рәисе Андрей Савельев сүзләренә караганда, республикада яшәүче һәр өч кешенең икесе үз куышын булдыруга яки торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ. Чынлыкта исә халыкның 35 проценты гына бу хыялын чынга ашыра ала.

– Яңа төзелүче йортлардан фатир алу өчен дәүләт ярдәме белән бирелә торган ипотека программасын озайту гына аз. Ташламалы программаларны икенчел торак базарына да кертергә кирәк. Әйтик, аннан фатир алырга теләүчеләргә дә 5–6 процент белән ипотека бирә башласалар, тотылган фатирларга да сорау артыр иде. Бу беренчел торак базары өчен дә файдага гына булачак. Ник дигәндә, иске фатирын сатучыларның күбесе шул акчаны яңа төзелгән йорттан зуррак фатир сатып алуга тотачак бит, – ди Андрей Савельев.

Финанс аналитигы Владимир Сагалаев фикеренчә, якын арада фатирның яңасы да, искесе дә күбрәк сатыла башлар дип өметләнергә кирәкми. Белгеч моны Үзәк банкның быел 1 декабрьдән беренчел кертем өчен ким дигәндә 10 процент акчасы булмаган кешеләргә ипотека бирү кагыйдәләрен катгыйландыруына бәйләп аңлата.

– Аның нигезендә банкларга беренчел кертем өчен җитәрлек күләмдә акчасы булмаган кешеләргә ипотека бирү отышлы булмый башлаячак. Шул рәвешле рәсмиләштерелгән ипотека кредитлары кискен кимеячәк. Бу исә – фатирлар да азрак сатылачак дигән сүз, – ди белгеч.

Владимир Сагалаев фикеренчә, торак сатылмагач, төзүчеләргә фатир бәяләрен дә азрак төшерергә туры киләчәк. Ел азагына кадәр фатирларның яңалары да, искеләре дә уртача 20–30 процентка арзанаячак, дип фаразлый ул. Шуңа якын арада торак шартларын яхшыртырга теләгән кешеләргә бу мөмкинлектән файдаланып калырга киңәш итә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Тырышлар бушлай йөри

Быел Татарстанда студентлар өчен «Транспорт гранты»ның гомуми күләме 60 миллион сум тәшкил итә. Аны 6 меңгә якын егет-кыз арасында бүләчәкләр. Транспорт акчасын мохтаҗ яки актив студентлар ала. Яшьләр эшләре министры урынбасары Софья Мостафина әйтүенчә, студентларга транспортта йөрү өчен акча 2011 елдан бирле түләнә.

Өч ел элек аның гомуми күләме 60 миллион сумга җиткерелгән. Шулай итеп, һәр ел саен 6 меңгә якын егет-кызга транспорт чыгымын каплауга бер тапкыр акча бирелә. Казанда бу – 11 мең сум, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Алабугада – 10ар мең, калган шәһәр һәм районнар өчен – 8әр мең сум.

Грант алуга гаризалар кабул итү тәгаллләнеп килә. Аңа югары һәм махсус урта уку йортларында көндезге бүлектә белем алучы студентлар дәгъва кыла. Грант бәйгесендә катнашу өчен уку турында белешмә яки зачет кенәгәсе тапшырырга кирәк. Акчаны яхшы укучыларга гына бирәләр.

Аз гына калган

Татарстанда төрле социаль объектларны капиталь төзекләндерү программалары – 98, ә күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү программасы 99,87 процентка үтәлгән. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин әйтүенчә, ремонт эшләре буенча барлыгы 21 программа тәгалләнгән. Нәтиҗәдә 12 миллиард 780,81 миллион сумлык эш башкарылып, 1744 корылма тәртипкә китерелгән.

Аерым алганда, мәгариф оешмаларын төзекләндерү программасына 317 бина кертелгән булган. Күптән түгел генә Мамадыш районында мәктәп файдалануга тапшырылган. Казан мәктәбендә төзекләндерү эшләре 81 процентка үтәлгән.

Сәламәтлек саклау өлкәсе оешмаларын ремонтлау программасы 44 объекттан тора. Соңгы ике атна эчендә Казанда, Әлмәт, Түбән Кама, Теләче һәм Лениногорск районнарында медицина учреждениеләре янә сафка баскан. Әлегә Чистай, Нурлат һәм Чаллы хастаханәләрендә ремонт дәвам итә. Программа 99 процентка үтәлгән.

Шулай ук программада каралган 753 күпфатирлы йортның 9ында төзекләндерү эшләре дәвам итә.

Алдан аяк киенәсе

Татарстанга грипп ка каршы вакцинаның соңгы партиясе кайтты. Белгечләр бу мөмкинлектән файдаланып, чиргә каршы бүгеннән үк чарасын күреп куярга киңәш итә. Ник дигәндә, быел Татарстанда грипп чоры аеруча катлаулы булачак дип фаразлыйлар. Белгечләр хәтта республикада дуңгыз гриппы йоктыру очраклары да күзәтелергә мөмкин дип кисәтә. Хәзерге вакытта Татарстанда 1,3 миллион кеше әлеге чиргә каршы прививка ясаткан. Моның өчен яшәү урыны буенча теркәлгән хастаханәгә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Исегезгә төшерәбез: узган атнада Татарстанда грипп йоктыруның беренче очрагы теркәлде. Ил күләмендә исә әлегә шундый 70 очрак исәпләнә.

Суык һәм бозлавык

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 30 ноябрьдә аз гына кар көтелә. Көндез –7…–12, төнлә –13…–18 градус. Пәнҗешәмбе – 1 декабрьдә урыны белән бераз кар явачак. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –7…–12, төнлә –12…–17 градуска кадәр төшәчәк.

Башлангыч фаразларга караганда, җомга – 3 декабрьдә дә суык, юлларда бозлавык саклана. Көндез һава температурасы –7…–12 градус чикләрендә тирбәлсә, төнлә –11…–16, урыны белән –19 градуска кадәр салкын булачак.

Мәктәп ашханәләре

Кайнар һәм тәмле булсын!

Быелгы уку елында Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе белгечләре 415 мәктәп ашханәсендә туклану тәртибен тикшергән. Шуларның 85 процентында төрле кимчелекләр ачыкланган. Кисәтүләрнең яртысыннан артыгы табак-савыт юу, ашханәне җыештыру, яшелчәләрне эшкәртүгә бәйле. Нәтиҗәдә 20 кило ризык ашханәдән алынган.

Роспотребнадзорның республика буенча идарәсе хәбәр иткәнчә, белгечләр мәктәп, бакчалардагы туклану тәртибен һәрдаим контрольдә тота. Тикшерү барышында ризыкның сыйфатына, яраклылык вакыты, саклау шартларына, маркировкалауга, хезмәткәрләрнең медицина тикшерүе нәтиҗәләре, ашханәләрдәге чисталык, меню һәм башка мәсьәләләргә игътибар итәләр. Яңа уку елында 2500дән артык ризык һәм чимал тикшерелгән. Мәктәпләрдә туклануны оештыру тәртибен бозучы вазыйфаи, юридик затларга карата административ чаралар күрелә. Әйтик, быелгы уку елында 264 очрак буенча штраф салынган.

Без туклану турында әти-әниләр, пешекчеләрнең фикерләрен белештек. «Балаларны ашаткан чагыбыз әле, эшебез бик кызу, бераздан шалтыратыгыз», – диде Балтач районы мәктәпләренең берсендә пешекче булып эшләүче Флүсә Габделхакова. Төшке аштан соң иркенләбрәк сөйләшергә җае чыкты тагын.

– Роспотребнадзор белгечләре еш килә. Ашауга таләпләр зур. Ризык кайнар булырга тиеш. Тикшерүчеләр аш, боткаларның температурасын тикшерә. Үзебез дә салкынны ашатмаска тырышабыз. Әмма аш-суның суынып киткән чаклары да була. Безнең ашханә аерым урнашкан. Балалар аяк киемнәрен урамнан салып кергәнче дә шактый вакыт үтә. Шуңа күрә температураны саклап җиткерә алмыйбыз, – ди Флүсә Габделхакова.

Пешекче әйтүенчә, менюны Казаннан җибәрәләр. Төшке аш бәясе – 55 сум.

– Балаларның шулпа ашыйсы килә. Рагу бар, ә токмач, борчак ашларын сагынып сөйләргә генә калды. Шулай ук манный, сөтле боткаларны да. Ай саен менюны үзгәртәләр, әмма ботка юк. Аның каравы пылау бар. Кишер, кәбестә салатларын бирәбез, винегрет каралмаган. Яратканы өстәтеп алса, талымлаганы ашамыйча, тәлинкәдә калдыра. Бигрәк тә бәрәңге боламыгы, токмач, карабодай, тавык ите яраталар. Кекс, корж кебек пешкән әйберләрне районндагы чәй йортыннан китерәләр. Укучылар ашаудан зарланмый. Укытучылар да шул ризыкны ашый бит, – диде ул.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Дмитрий ПЕСКОВ, Россия Президентының матбугат секретаре:

Халыкның теләктәшлеге – Путин өчен иң мөһиме. Путин һәрвакыт әнә шул теләктәшлеккә нигезләнеп эшли һәм карарлар кабул итә. Бу хакта үзе дә бер генә әйтмәде инде. Путинның феномены халыкның ышанычыннан гыйбарәт. Бу аның эшчәнлеге нәтиҗәле булганын, ә иң мөһиме, чыннан да, халыкның ихтыяҗларына туры килгәнен күрсәтә.

(Журналистлар белән очрашуда сөйләгәннәрдән)

ТАТАРСТАНДА – АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ЯРМИНКӘЛӘРЕ

Татарстан шәһәр һәм районнарында узган авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә 1,2 миллиард сумлык продукция сатылган. 10 сентябрьдә башланган ярминкәләрнең ахыргысы 24 декабрьдә булачак.

12 ЯРМИНКӘДӘ КҮПМЕ ПРОДУКЦИЯ САТЫЛГАН?

9705,4 тонна бәрәңге
192,2 тонна сөт
1285,2 тонна ит
1,5 миллионданә йомырка

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя 444 сум 54 тиен**, гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя 980 сум 10 тиен**, гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙ: ДАВЫЛ ОЗАККАМЫ?

Җир шарында шомлы хәбәрләр әйләнәсе дәвам итә. Белоруссия тышкы эшләр министры Макейның кисәк үлеме мәгълүмат кырында әллә никадәр имеш-мимеш һәм шөбһә тудырды. Сау-сәламәт, бернидән дә зарланмаган кешенең көтмәгәндә үлеп китүе болай да серле тоела. Дөньякүләм вакыйгалар куеруга катнашы булган илнең мөһим сәясәтчесе саубуллашырга да өлгермичә мәңгелеккә күчә икән, фаразлар каршылыклы була, әлбәттә. Төрле калибрдагы сәясәтчеләр «Үтерделәрме, үзе үлдеме?» дигән сораугa җавап эзли. Рәсми Минск берни дә эндәшми. Лукашенконың үз пешекчеләрен, хезмәтчеләрен һәм сакчыларын алыштырырга кушуы турында хәбәрләр бар. Минск, Макей җәсәденә химик-токсикологик анализ ясау өчен, Израильнең дөньякүләм әйдәп баручы лабораторияләренә мөрәҗәгать итәчәк, дигән сүзләр дә ишетелә. Әмма болар берсе дә имеш-мимеш дәрәҗәсеннән узган яңалыклар түгел.

Дөньяның башка почмакларында да аһ итәрлек нәрсәләр тулып ята. Әмма атна ахырында төп яңалыклар мәйданы Кытайга күчте. Анда ковидка каршы көрәш, бөтен чикләрне үтеп, мантыйкка каршы килә башлады. Кешеләргә нәрсә күбрәк зыян салуын да аңлап булмаслык хәл туды: көрәш коронавирусның үзенә караганда куркынычракка әверелде. Катардагы футбол буенча дөнья чемпионатын Пекинда шундый итеп трансляцияләделәр: трибуналар томан эчендә һәм берни дә күренми иде. Битлексез утырган фанатларны күреп: «Ни өчен алар иркендә?» – дигән сорау бирерлек булмаска тиеш иде. Әмма гадәттән тыш көчле тыюлар һәм мәгълүматны яшерү булышмады. Гайканы артык нык кысып борсаң, кысыр әйләнеш барлыкка килә бит. Анда да шуңа охшаш вазгыять туып килә.

Иң башта 23 ноябрь көнне Үзәк Кытайдагы iPhone җитештерүче завод эшчеләре каршылык күрсәтте. Мәгълүмат кырына эшчеләрнең сак хезмәте һәм полиция белән бәрелешүләрен төшергән видео чыкты. Тест тапшыру кабиналары җимерелгән, бер автомобильне әйләндереп каплаганнар иде. Гадәттә Кытай компартиясе, фетнә чыкканда, вазгыятьне бик тиз кулга ала. Бу юлы кырыс чаралар тиешле нәтиҗәне бирмәде. Гыйсъянчылык дәрте башка төбәкләргә дә таралды. Шанхай урамнарында мәйданга чыккан халык: «Коммунистлар партиясе, кит!» – дип кычкырды. «Без ирекә чыктык, вируска тикшеренергә түгел!», «Без демократия телибез, диктатура түгел!», «КПКны җимерергә!» дигән тавышлар да яңгырады. Стихияле халык хәрәкәте Гуанчжоуда, Урумчида, Уханьда һәм башка шәһәрләрдә сәяси өермә тудырды. Бикләнгән йортларның берсендә янгын чыгып, кешеләр үлгәч, ризасызлык дулкыны көчәйде. Запас чыгу юллары бикле, төп ишекләр дә ковид-йозакта. Менә шул хәл дөянең сыртын сындырган салам бөртеге ролен уйнады. Интернет челтәренә чыккан фетнә видеолары озак тормый, юк ителә, әмма хәлләр яшерерлек түгел. Си Цзиньпин соңгы съездда хакимияттәге балансны җимерде. Тыйнак кына оппозициядә торган «комсомоллар» төркеме идарәдән читләштерелде. Нәкъ менә шулар ковид-чикләүләргә каршы иде. Алар, вазгыятьтән файдаланып, баш күтәргән халыкның юлбашчыларына әверелерме, әйтү кыен. Әмма теләсә кайсы диктатура ахыр чиктә мәтәлчек ата – монысы хак. Әлегә кытай валютасының долларга каршы курсы түбәнәя.

Россиядә

РОССИЯ ӨЧЕН ЯҢА ФИНАНС ДӨНЬЯСЫ

Кремль санкцияләр коллыгыннан чыгу юлларын эзли. Россия өчен төп проблема – акча күчерү. Илләр арасында финанс агымнары бикләнә икән, сәүдә юк дигән сүз. Берәү дә сиңа комплектлаучы детальләрне бушка китереп бирмәячәк, технологик товарларын да сатмаячак, санкцияләр астындагы углеводородларны алудан да баш тартачаклар. Әлегә дөньякүләм акча алмашуны һәм сәүдәне Американың JPMorgan, Bank of America һәм Citigroup банклары үз контролендә тота. Әйтик, «Ак Барс» банкында валютаң бар, аны Кытайга күчереп, товар алырга телисең икән, югарыда искә алынган банклар финанс операциясен бик җиңел өзеп куя алалар. Чит илләргә валюта күчерергә теләгән физик затлар да шундый хәлдә: американнар, тели икән, хисабыңны бикли дә куя. Чит илләргә барып хисап ачып, аны файдалана башласаң да, тулысынча имин була алмыйсың. Россияле икәнсең, син түбән сортлы (изгой). Гел ут йотып, хәвеф эчендә яшисең. Әйләнеч юллары бар аның үзе. Бер долларга тиңләштерелгән махсус криптовалюталар бар, курслары үзгәрми. Монда шуны сатып аласың да, теге якка чыккач, бер криптоны бер долларга алыштырасың.

Менә шул вазгыять Россия сәнәгатенең түбәнгә китүенә төп сәбәп булып тора да. Октябрь аенда сәнәгатьнең кайбер тармакларында җанлану һәм күтәрелеш булса да, нефть чыгару һәм йөк автомобильләре җитештерү түбәнгә киткән, мәсәлән. Әлегә Көнбатыш илләре «кара алтын»га иң зур бәяне килештерә алмый интегәләр, килештерсәләр, Мәскәү андый бәядән «кара алтын» сатмау ягын каера. Бу углеводород тармагын тагын да түбәнгәрәк ташлаячак. Кызыгы шунда: Көнбатыш нигездә 65–70 долларлык «түшәм» турында сүз алып бара, ә Россия нефте үткән атнада Новороссийск һәм Приморск портларыннан 52 долларга озатылды.

Килеп туган хәлне төзәтү өчен, американнарга бәйле булмаган түләү системасы эзләргә туры килә. «Ясалма интеллект дөньясына сәяхәт» дигән конференциядә Путин яңа халыкара түләүләр системасы булдырырга чакырды. Путин күзаллавынча, бу система банкларга бәйсез булырга һәм ниндидер өченче як аңа тыкшына алмаска тиеш. Президент, ачынып: «Существующая сегодня система международных платежей дорогостоящая, система ее корреспондентских счетов и регулирование находятся под контролем узкого клуба государств и финансовых групп. По сути, они хозяева жизни, они монопольно все контролируют», – диде. Мәскәү Үзәк банкларны цифрлы валюталарга күчәргә чакыра.

Андый системалар, чынлап та, эшләнә алар. Әмма аларның шулай ук нечкә яклары бар. Бердән, аларны кертү өчен, зур сәяси йогынтыга, хәрби куәткә, көчле икътисадка ия булырга кирәк. Газны сумнарга сатуның ничек төгәлләнүен күрәбез бит. Ахыр чиктә берәү дә сумнар белән түләмәде аңа, Көнбатышка зәңгәр ягулык озату гына тукталды диярлек. Икенчедән, цифрлы коллыкка төшү куркынычы халыкларда көчле каршылык хәрәкәте уятып килә.

ЮЛ БИРЕГЕЗ, «АУРУС» КИЛӘ

«Атлант», «Арго», «Аурус Комендант». Татарстанда җитештерелә башлаячак яңа машиналарның исемнәре бу. Заводка каршы санкцияләр кертелүгә карамастан, «КАМАЗ» да бер урында таптанып тормый. Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары – РФ сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республиканың автомобиль сәнәгате өлкәсендәге яңалыклар белән таныштылар.



tatarstan.ru

Чаллыга эш сәфәре кысасында Денис Мантуров һәм Рөстәм Миңнеханов «КАМАЗ»ның җитештерү цехларын карады. Мәскәү кунагына автозаводта җитештерелүче яңа модельләрне күрсәттеләр. Компания генераль директоры Сергей Когогин билгеләп үткәнчә, завод барлык йөкләмәләрне тулысынча үти һәм илнең транспорт иминлеген тәэмин итә. Санкцияләр булуга карамастан, К4 һәм К5 төрендәге йөк машиналары җитештерүне дәвам иттерәләр. Айлык күрсәткеч киммендә 100–150 автомобиль тәшкил итә.

Денис Мантуров һәм Рөстәм Миңнеханов «Алабуга» махсус икътисади зонасында да булды. Биредә алар «Соллерс» бренды белән җитештереләчәк автомобильләрне карады һәм эшне оештыру проектын башлап җибәрделәр. Американың «Форд» компаниясе ил базарыннан киткәннән соң, «Соллерс» яңа автомобильләр җитештерүне җайга салмакчы. Коммерцияле яңа җиңел йөк машиналарының исемнәре дә билгеле – «Атлант» һәм «Арго». «Соллерс»та елына 30 мең автомобиль җитештерергә ниятлиләр. Яңа проектка инвестицияләрнең гомуми күләме 5 миллиард сум тәшкил итәчәк, дип фаразлана.

Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, республика «Соллерс» белән хезмәттәшлек итүне югары бәяли. «Компания күчеш чорында да хезмәт коллективын саклап калды. «Соллерс» коммерцияле җиңел машиналар җитештерүне җайга салды. Бу продукциягә ил базарында ихтыяҗ зур. Яңа проект республика өчен бик мөһим: бу – эш урыннары да, бюджетка керемнәр дә», – диде ул. «Соллерс» мәйданында алдагы дүрт айда җитештереләчәк машиналарның сатып алучылары билгеле инде.

Татарстанда тагын бер яңа машина җитештерелә башлады. Денис Мантуров һәм Рөстәм Миңнеханов «Аурус Комендант» автомобилен серияле җитештерүгә старт бирде.

«Аурус Комендант» – теләсә нинди юлдан йөри торган люкс класслы машина. Җитештерүгә кирәкле запас частьларның күп өлеше илдә, шул исәптән, Татарстанда җитештерелә. Моны Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары да ассызыклады. «Әлеге машина компонентларының 70 проценты үзебезнеке», – диде ул. Ел ярымга якын вакыт эчендә завод эш өчен кирәкле барлык юнәлешләрне җайга салуга ирешкән һәм менә күпләп җитештерүне башлау эшенә тотыналар. Денис Мантуров һәм Рөстәм Миңнеханов сәнәгать линиясе белән таныште, автоматлаштырылган идарә системасын карады. РФ сәнәгать һәм сәүдә министры әйтүенчә, алга таба «Аурус» брендын авиация һәм суднолар төзү тармакларында да үстерү күздә тотыла. Ул завод эшен югары бәяләде.

Кунаклар яңа автомобильдә йөреп тә карады. «Аурус Комендант» – люкс класслы машина булуына карамастан, махсус безнең илдә куллану шартларына туры китереп төзелгән. Куәте генә ни тора, автомобильнең двигателе 598 ат көченә ия. Компания мәгълүматларына караганда, тәүге автомобильләрне киләсе елның беренче чирегендә сата башлаячаклар. Заказларны сентябрь аенда ук җыя башлаганнар инде. Әйтүләренә караганда, яңа машинаның бәясе 33,7 миллион сумнан башланачак. Рәхәттә йөрисең килсә, түләргә дә туры киләчәк!

Рөстәм Миңнеханов Чаллыда «КАМАЗ-мастер» командасы вәкилләре белән дә очрашты. Билгеле сәбәпләр аркасында, быел спортчылар «Дакар» ярышларында катнашмый. «Бүгенге кебек катлаулы шартларда без Ватаныбыз белән бергә», – диде команда җитәкчесе Владимир Чагин. Узышта катнашмасалар да, тик утырырга вакытлары юк. Быел якташларыбыз «Дакар-2022» һәм «Ефәк юлы-2022» ралли-марафоннарында үз өстенлекләрен раслап күрсәтте инде. Ралли-рейдлар буенча Россия чемпионатында да безнекеләр беренче. Ел дәвамында спорт йөк машинасын тагын да камилләштергәннәр. Аңлашыла ки, үзебездә җитештерелүче запас частьларга өстенлек бирәләр. Яңа техниканы киләсе елның 6–15 июль көннәрендә Казан – Уфа – Магнитогорск – Оренбург – Самара – Саратов – Волгоград – Липецк – Мәскәү маршруты буенча узачак «Ефәк юлы»нда сынап караячаклар. Президент яңартылган йөк машиналарын югары бәяләде. Нинди алгарышка ирешелгәнен аңлар өчен, яңасы белән беррәттән, 1996 елда җитештерелгән йөк машинасында йөреп тә карады. «КАМАЗ»лар юлда сынатмый», – диде республика башлыгы.

Ярдәм кулы

Игътибарлырак булыгыз! Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов министрларга, шәһәр һәм район башлыкларына әнә шулай дип киңәш итте. Инвалидлар декадасы алдыннан җитәкчеләргә эш тә кушты.

Татарстан Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә республикада узган атнада яуган бозлы яңгырның зыяны турында сөйләштеләр. «Табигать бәла-казасы аркасында шактый торак пунктлар утсыз калды, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Барыннан да бигрәк Чүпрәле һәм Буа районнары зыян күрде. Шулай ук Алексеевск, Кама Тамагы, Нурлат, Спас һәм Тәтеш районнарында гадәттән тыш хәл турында билгеле».

Президент сүзләренә караганда, бозлы яңгыр аркасында, 10 меңнән артык кеше яшәгән 86 торак пункт, социаль әһәмияттәге 22 бина утсыз калган. «Явым-төшемнән соң юллар бозланып катты. Бу исә җәмәгать транспорты эшендә кыенлыклар тудырды, – дип тә ассызыклады республика башлыгы. – Кыш әле башланды гына. Бозлы яңгырлар тагын кабатланырга мөмкин. Шуңа күрә министрларга, шәһәр һәм район башлыкларына табигать бәла-казасы нәтиҗәләрен тиз арада юкка чыгарырга әзер торырга кирәк».

Рөстәм Миңнеханов 3 декабрь – Халыкара инвалидлар көне турында да искә төшерде. «1–10 декабрьдә республикада Инвалидлар декадасы узачак. Дәүләт хакимияте һәм җирле орган җитәкчеләренә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә ярдәм чараларын арттыру, әлеге уңайдан төрле чаралар үткәрүгә бәйле эш кушылды инде», – диде Президент. Аның сүзләренә караганда, соңгы елларда республикада инвалидларга ярдәм итүдә шактый эш башкарылган. «Тик хокукый, социаль, ирекле хәрәкәт итүгә бәйле киртәләрне юкка чыгару өчен күп эшләргә кирәк әле», – диде Рөстәм Миңнеханов. Президент, түрәләргә мөрәҗәгать итеп, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә тагын да игътибарлырак булырга киңәш итте. Ул, инвалидларны борчыган мәсьәләләрне хәл итү өчен, халык белән очрашулар үткәрергә кушты.

Кайнар һәм тәмле булсын!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Блогер Люция Алиевага Казан азык-төлек һәм социаль туклану департаменты уздырган «Әни – темада» дигән очрашуларда еш катнашырга туры килә. Билгеле булганча, бер төркем блогерлар, ашханәләргә барып, үзләре дә мәктәп ризыгыннан авыз итеп карый, башка укучыларның да ничек ашаганын күзәтә.

– Казан мәктәпләрендә туклануга таләпләр бик җитди. Көектә мәктәп ачылгач, балаларны шунда күчердек. Башта әйбәт ашаталар иде. Хәзер продукцияне Питрәчтән китерә башлаганнар. Балалардан салкын, тәмсез, тозсыз дигән сүзләр ишеткәлибез. Башлангыч сыйныф укучылары арасында ипи кимереп йөрүчеләр дә бар. Ашханәдән алып чыгарга рөхсәт итмәгәч, икмәк кисәген авызга тыгып алып чыгабыз, диләр. Өйгә ачыгып кайталар. Кайтуга тизрәк суыткычка ябышалар. Җаем чыккач, мәктәпкә барып, җитәкчелек белән туклану проблемалары турында сөйләшергә җыенам, – диде Люция Алиева.

Икенче бер әнидән дә сораштык. «Улым мәктәптән, бик тәмле кишер салаты белән токмач бирделәр, дип сөенеп кайта. Хәләл булмагач, ит ашамый. Шуңа күрә туклану сыйфатына бәя бирә алмыйм», – диде Гүзәлия Галиәхмәтова.

Әти-әниләрне борчыган проблеманы Питрәч районы мәгариф идарәсенә җиткердек.

Мәгариф оешмаларындагы ашханәләрдә пешекче булып сабыр һәм сәламәтлеге нык булганнар гына эшли аладыр, мөгаен. Әнә бакчада эшләп алган Ралия Шәрәфиеваның түземлеге бер елга гына җиткән.

– Менюга үзең берни өсти алмыйсың, кушканны гына пешерәсе. Бер граммы да ким булмаска тиеш. Тәмле килеп чыкмаса, гаепне пешекчедән күрәләр. Чисталык мәсьәләсе дә – беренче урында. Бүген тикшерүчеләр килмәсә генә ярар иде, дип теләп тора идек. Штраф салганнары булмады анысы. Әмма ярты сәламәтлегем бетте, шуңа күрә эштә озак түзә алмадым, – диде Ралия Шәрәфиева.

Сәрия МИФТАХОВА

КУРКЫНЫЧ БОЗ ТҮГЕЛ

Игенчелек

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, быел көз хуҗалыкларда 472 мең гектар көзге культуралар чәчелгән. Шуның 378 мең гектары – бодай, 89 мең гектары – арыш. Азмы бу, күпме? Чагыштыру өчен: 2020 елда көзге культураларның мәйданы 529 мең гектар булса, узган ел ул нибары 479 мең гектар, ягъни 50 мең гектарга азрак мәйданда чәчелгән.

Автор фотосы

Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Залаков әйтүенчә, быел көзге культураларның саклanышы узган еллар белән чагыштырганда күпкә яхшырак.

– Россельхозцентрның Татарстандагы филиалы белгечләре тарафыннан алып барыла торган даими күзәтүләр нәтиҗәсе күрсәткәнчә, чәчүлекләрнең 96 проценты кышны яхшы хәлдә каршылый. Кышкы салкыннарга бирешмәс өчен уҗымнарга 20 процент шикәр кирәк булса, хуҗалыкларда әлеге күрсәткеч 26–30 процентка җитә, – ди министр урынбасары.

Табигать шартлары әледән-әле үзгәреп тора. Шуңа бәйле рәвештә игенчеләр алдында да ел саен диярлек төрле кыенлыклар барлыкка килә. Быелгы көз дә шундыйлардан. Югыйсә берничә көн элек кенә җирләрне туңдырып, уҗымнарны ап-ак кар каплаган иде. Кышны бик яхшы каршылаучы уҗымнар ап-ак юрган астында тыныч кына ятар дисәк, ничә көн дәвамында яңгырлар яуды. Боз элпәсе әсирлегендә калган уҗымнарга зыян килмәсме? Уҗымнарны каплап алган боз катламыннан ничек котыласы? Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты галимнәре – авыл хуҗалыгы фәннәре докторы Сергей Пономарев һәм көзге культуралар лабораториясе җитәкчесе Ирина Фадеева белән Лаеш районы Олы Кабан авылы янындагы тәҗрибәләр кырын урап кайтырга булдык.

– 2022 елның көзе игеннәр өчен шактый катлаулы чор булды. Август аенда тәүлекнең уртача температурасы гадәти еллардагыдан 8,1 градуска җылырак иде. Өстәвенә күп районнарда бер тамчы яңгыр яумады. Ә бит бу чор – көзге культуралар чәчү өчен иң кулай вакыт. Туфрак катламында дым булмаса да, чәчү эшләрен вакытында башкарып чыга алган хуҗалыклар отты. Сентябрьнең беренче ункөнлегендә республиканың барлык районнарында диярлек әледән-әле явып узган яңгырлар игеннәргә тигез шытарга һәм кыска гына вакыт эчендә дәррәү күтәрелеп китәргә мөмкинлек бирде. Көзге бодай һәм арышның актив үсеше 20–21 октябрьгә кадәр дәвам итте. Уҗымнар бу вакыт аралыгында үзләренә җитәрлек күләмдә файдалы матдәләр тупларга өлгерде, – ди 30 елдан артык көзге культуралар селекциясе белән шөгыльләнүче Ирина Фадеева.

Сүз уңаеннан, яңарак кына Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кулыннан «Фидакарь хезмәт өчен» медале алган Ирина Фадеева тарафыннан уйлап чыгарылган «Универсиада», «Солтан», «Казан 560», «Өмет», «Дарина» һәм дистәгә якын көзге культуралар республикада иң югары уңыш бирүче сортлардан санала. Әтнә, Апас, Актаныш, Буа, Саба һәм башка район хуҗалыкларында әлеге сортларның мәйданы елдан-ел арта бару да шуны раслый.

Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләге иясе, Россия Фәннәр академиясенең В.П. Мосолов исемендәге премиясе лауреаты, дөньякүләм дәрәҗәле селекционерларның берсе булган Сергей Пономарев та соңгы вакытларда өстән явып торган карлы яңгырлар уҗымнарның торышына әллә ни зыян салмас дип өметләндерә. 37 ел дәвамында иген кырларында селекция, яңадан-яңа сортлар белән тәҗрибәләр уздыручы галимгә бу еллар эчендә һава шартларының төрлесен күрергә туры килгән. Көзге культураларның 8 яңа сортын уйлап чыгарып, һәркайсына Россия күләмендә патент алуга ирешкән галим ул.

– Көздән оптималь срокларда җир куенына кереп, көзге кояш нурларында ныгып калган, ашлама һәм корткычларга каршы препаратлар белән эшкәртелгән көзге культуралар, һава торышы никадәр генә катлаулы килсә дә, язын дәррәү күтәрелеп китәргә сәләтле. Андый уҗымнарга быелгы һава шартлары да куркыныч түгел, – диде ул, кышны берничә сабакка ныгып каршылаучы игеннәргә карап.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белгечләре әйтүенчә, хуҗалыклар көзге культураларны никадәр күбрәк мәйданда чәчсә, шулкадәр отышлы. Чәчү мәйданнарының яртысыннан артыгын көздән чәчеп калдырган Спас (56%), Яшел Үзән (45%), Әлки һәм Югары Ослан (44%) районы хуҗалыкларының эш тәҗрибәсе дә шуны раслый.

Шунысы сөендерә: Татарстан хуҗалыкларында үзебезнең галимнәр тарафыннан уйлап чыгарылган сортларны елдан-ел күбрәк файдаланалар. Әйтик, Ирина Фадееваның «Казан 560» көзге бодай сортын быел 100 мең гектарда чәчкәннәр.

– Без андый хуҗалыклар белән элемтәдә торабыз. Кулдан килгәнчә ярдәм дә итәбез. Әледән-әле үзгәреп торучы һава шартларына күбрәк яраклаштырылган, корылыкка да бирешми торган сортлар быел да сынатмый. Бергәләшеп исәпләп карадык: үзебезнең сортларны файдалану быел гына да хуҗалыкларга 197 миллион сум өстәмә табыш биргән, – ди Ирина Фадеева.

Камил СӘГЪДӘТШИН

ТОРНАЛАР ТӨШКӘН ҖИРДӘ

Авыл капкасы

«Безнең авылга дөньяның дүрт ягыннан җиде юл кайтып керә. Һәр җиде юлдан кайтканда авыл, минем туган йортым җиде төрле булып күренә», – дип яза Мөхәммәт Мәһдиев «Торналар төшкән җирдә» әсәрендә. Арча районының Гөберчәк авылы бүген ничек яши? «ВТ» хәбәрчесе бөек әдип атлаган сукмакларны урап, авылның яшәеше белән танышып кайтты.

Альберт Каюмов

Масра басуына торналар һаман да төшәме? «Торналарны сирәк кеше күрә, алар бик биектән оча. Тавышлары әллә ни ишетелмәсә дә, үзәкне өзәрлек», – ди Гөберчәктә яшәүчеләр. Авыл кешеләре, торналар тавышын күңелендә йөртсә дә, сагышка чумып яши торганнардан түгел.

Иң гадәти авыл

Гөберчәктә бүген 260 кеше яши. Элеккеге белән чагыштырганда халкы күпкә кимегән. Йортлар төзек. Терлек асрап көн күрәләр, хәер, мал-туар тотмаганнар да бар. Элек исә итеген дә басканнар, шәлен дә бәйләгәннәр. Хәзер һөнәрчеләр алай күп түгел. Башлангыч мәктәп ишегендә – йозак, ул 2014 елда ук ябылган. Шуннан бирле балаларны Сикертән мәктәбенә автобус белән йөртәләр. Клуб, музей, китапханә эшли.

– Авылыгызда нинди үзенчәлекләр, аерылып торган кешеләр бар? – дип сорагач, барыбыз да бертөрле инде, диештеләр. Мөхәммәт ага әйткәнчә килеп чыга түгелме соң? «Безнең авылдан бер генә герой да, бер генә академик та чыкмаган. Гап-гади, иң гадәти авыл. Анда зур сулар, таулар, иркен болыннар юк. Кыялар юк. Тагын бик күп нәрсә юк. Бөтен булган байлыгы – урман, чишмәләр һәм кешеләр», – дип язган бит ул.

Тик урам буйлап йөри торгач, кызыклы кешеләре очрады тагын. Әнә Радик Солтанов чыккан сөяк, буыннарны утырта. Халык табибы йортыннан кеше өзелми. 85 яшьлек Васил Әминов исә озак еллардан бирле халык сынамышларын язып бара икән. Элеккеге колхоз рәисе болынга печән өләшергә чыкканда, уракка төшкәндә, көннең ничек буласын Васил абыйдан сорый торган булган. Һава торышын язган дәфтәрләре берничә аның. Кайберләре саргаеп беткән инде.

– Яңгырмы, кармы, бозмы – һәр көн турында язып барам. Җәй белән кышны чагыштырам, күп очракта туры килә. Фәлән көнне буран икән, җәен шул вакытта яңгыр ява. Ялгышулар бик сирәк була, – ди халык синоптигы.

Иртәгә ак келәт салачак

Утыз елга якын колхоз рәисе булып эшләгән Габделбәр абый Фәйзрахманов: «Гөберчәк халкы ул шундый: берсе мунча салса, икенчесе иртәгә ак келәт төзи башлый», – дия торган булган. Авылның йөзе үзгәрәме?

– Үзгәрә, әлбәттә. Йортларның элеккеге бизәлешен тулысынча саклап калу юк инде. Заманага ияреп, кешеләрнең өен, каралты-курасын яңартасы, матурайтасы килә, – ди Мөхәммәт Мәһдиев музее директоры Халидә Габидуллина.

Аның әйтүенчә, халыкта көнчелек көчле. Берәү яңа капка-койма корган икән, күршесе дә аннан калышырга тиеш түгел! Һәм ул икенче көнгә үк шул эшкә план кора башлый. «Мөхәммәт абый шушы авылга кайтса, ул аны таныр идеме икән? Элеккеге буынның яшәеше, холкы, күзаллавы хәзерге кешенекеннән бик нык аерыла», – ди Халидә ханым, үз-үзенә сорау биреп.

Авылда кич утыру, күршегә йөрү гадәте дә бетеп килә икән. Коймалар биек итеп ясалган, капкаларның исә ачыгы да, ябыгы да бар. Урамда кем йөрмәс дип шикләнеп, итәкҗиңнәрен җыеп йөриләр.

– Авыл үз эченә йомылып бара, кеше кыргыйлана. Бердәмлек, ярдәмләшү кими. Элек әҗәткә сорап тора идек. Сораганда – бер, бурычны керткәндә, күрше ишеген икенче тапкыр шакыйсың. Элемтә өзелми иде. Хәзер мондый хаҗәт юк. Барыбызның тормышы җитеш. Кирәк икән, товарны заказ буенча өйгә үк китерәләр. Өмәләр дә, кул алмаш эшләүләр дә бетеп бара, – ди Халидә ханым.

Геройлары кем булыр?

Буыннар алмашы дәвам итә. Сугышта катнашканнарның, тылда эшләгәннәрнең берсе дә калмаган. Сугыш чоры балалары – 14. Мөхәммәт абый бигрәк тә өлкәннәрдән мәгълүмат җыя торган булган.

– Ул, шәһәрдән кайтуга, тизрәк капка төбенә килеп, хәл белешер иде. Ике кулы да гел артта. Язучылыгы белән мактанып йөрмәде. Дөресрәге, без аның язучы икәнен белмәдек тә. Абыстайның малае итеп кабул итә идек. Сөйләшә башлауга, үзе дә сизмәстән, авылның тарихына кереп китәр иде, – ди авыл агалары. – Без аңа гомер буе рәхмәтле. Шушында туганлыктан, музее булганлыктан, авылга бик иртә асфальт юл килде. Юлсызлык – халыкны газап чиктергән әйбер бит ул.

Мөхәммәт абый исән булса, әсәрләрендә тел мәсьәләсен, авылның кыргыйлашуын яктыртыр иде. Халидә ханым әнә шулай дип күзаллый. «Бүген авыл баласы, белсә дә, белмәсә дә, синең белән русча сөйләшмәкче булып маташа. Мөхәммәт абый моңа бер дә риза булмас иде», – ди ул.

Авылдан шәһәргә китү проблемасы монда да бар. Яшьләрнең күңеле калага тартыла... Авылда халык саны кими. Читтә яшәүчеләр Гөберчәкне бик нык сагынып кайта икән. Нигезләре булмаганнар, зиратка барып, әрвахларга дога кыла, аннан авыл урамнарын әйләнеп, үткәннәрне искә төшерә. Бу очракта Мөхәммәт аганың «Бәхилләшү» романындагы шушы өзек искә төшә.

> ...Әйе, авылдан ник киттем? Моның сәбәпләре кайда? Ильяс ник үз авылында түгел? Авылны тергезергә кирәк дип сөйләп тә, мин нигә анда күченеп кайтмыйм? Моның сәбәбе нәрсәдә? Кайда? Йомгакның очы кайда? «Пәри тап, тап, биш балаңны буармын, бүген төнлә калдырмам, үзеңне дә буармын». Бала вакытта, үлән арасына төшеп, берәр әйберебез югалса, шулай такмаклый идек, һәм пәри, буылып үлүдән куркып, һичшиксез, теге әйберне табып бирә иде. Ә менә безнең сукмакларның башы кайда? Пәри, тап...

«Авылдан ник китәләр?» дигән сорауга Мөхәммәт Мәһдиев тә җавап таба алмаган. Беткән авыл сукмакларыннан йөргән журналист буларак, минем дә төгәл генә җавап ишеткәнем юк әле. Һаман бер сүз – эш юк, юл юк... Ни өчен китәләр? Бәлкем, бу сорауга бергәләп җавап эзләрбез.

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Геральдика өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы рәисе **Хәйретдинов** Рамил Равил улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың төзелеш тармагын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары **Абдуллин** Ринат Әзһәр улы; республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Казан шәһәренең «Ак Барс» физкультура спорт берләшмәсе» спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе директоры **Никулин** Павел Николаевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Газпром төбәкарагаз Казан» акционерлык җәмгыятенең шартнамәләр үтәлешен контрольдә тоту идарәсе башлыгы **Бережнев** Сергей Юрьевич, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының матди-техник тәэминат һәм дәүләт заказы бүлеге әйдәүче белгече **Ханов** Илдар Индус улы; күпьеллык намуслы хезмәтләре, мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсенә квалификацияле белгечләр әзерләүгә өлеш кертүләре өчен «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Долгова** Ирина Ивановна, «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Хрущева** Лариса Гавриловна; транспорт өлкәсендә күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Зеленодольск сөт эшкәртү комбинаты» акционерлык җәмгыяте автоколоннасы автомобиль йөртүчесе **Дубов** Валерий Александрович; прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Наумова** Надежда Михайловна; геральдика өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы рәисе урынбасары **Салихов** Радик Рим улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы әгъзасы **Бушканец** Григорий Моисеевич, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институты директорының фәнни эшчәнлек буенча урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы эксперты **Вәлиев** Рафаэль Миргасыйм улы, «РесурсоЭнерго-Эффективные Проекты» ябык акционерлык җәмгыяте директорының гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары **Дәүләтшин** Әмир Заһретдин улы, **Җәләлова** Нәҗибә Гамирҗан кызы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советының җаваплы секретаре **Миңнуллин** Илнур Рафаэль улы, «Россия Геральдистлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасы идарәсе башкарма директоры, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы эксперты **Моченов** Константин Федорович, Казан шәһәренең «Рок мәктәбе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең клуб формированиесе җитәкчесе **Сафин** Илсур Кариб улы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбе деканы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы эксперты **Ситдыйков** Айрат Габит улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, әтисе
ЗАРИПОВ Ринат Абдрахман улы
кинәт вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Зарипов Айрат Ринат улының авыр кайгысын уртаклаша.

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе, әтисе
ЗАРИПОВ Ринат Абдрахман улы
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Зарипов Айрат Ринат улының авыр кайгысын уртаклаша. Мәрхүмнең урыны җәннәттә булсын.

«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе коллективы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Ринат улы Зариповның
әтисе
вафат булу сәбәпле, якыннарының һәм туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Ватан хакына

ЛУГАНСКИГА ЯРДӘМ ИЛТЕП КАЙТКАН АЛМАЗ ГЫЙМАТДИНОВ:

«ЯХШЫГА ӨМЕТЛӘНИК!»

А.Гыйматдиновның шәхси архивыннан

Без монда алар өчен кайгырып, борчылып, кайтмаслар, дип утырсак, егетләребез нишләр? Луганскига кадәр барып, туганы Раил Габдрахмановка машина тапшырган Алмаз Гыйматдинов шулай ди. Егетләр белән аралашып, аларның көчле рухларына сокланып кайткан алар.

Алмаз Гыйматдинов – Россия Герое исеменә лаек булган Әлки егете Раил Габдрахмановның икетуган абыйсы. Энесе белән язышып, мөмкинлек булганда, телефоннан сөйләшеп торалар.

– Сокланам мин аңа! Гадилегенә, ярдәмчеллегенә, батырлыгына сокланам. Сайлаган һөнәре үзенә туры килеп тора. Хәрби булу – тыныч тормышта да җиңел эш түгел. Бүгенге шартлар турында әйтеп тә тормыйм инде. Аннан соң, Россия Герое исемен дә теләсә кемгә бирмиләр бит. Аның бу исемгә лаек булуын белгәч, бик горурландым. Үзебезнеке бит! – дип сөйләде Алмаз.

Шулай бер сөйләшкәндә, Алмаз туганының машинасы шартлавын белгән. Раил үзе йөк машинасында йөргән.

– Җиңел машина кирәк инде сиңа, дигәч, начар булмас иде, диде ул тыйнак кына. Сорамасам, әйтмәс тә иде әле. Зарлана белми ул чөнки. Без исә туганнар белән сөйләштек тә, акча җыешып, «Шевроле-Нива» машинасын сатып алдык. Машинаны яхшылап караттык, кирәк җирен яңарттык. Шуннан соң машинаны кием-салым, инструментлар, азык-төлек ише кирәк-ярак белән шыплап тутырдык та Раилнең әтисе Наил абый белән юлга чыктык, – ди әңгәмәдәшебез.

Луганскига ике машинада барган алар. Юл авырлыкларсыз булмый инде, ди Алмаз. Барганда да, кайтканда да кат-кат тикшерү аша узарга туры килгән.

– Аңлашыла да инде, төрле кеше булырга мөмкин бит. Луганскига килеп җитүгә, хәрби частьлары урнашкан җиргә юл тоттык. Ул көнне Раил үзе башка җирдә иде, безне дуслары каршы алды. Очраштык, таныштык, сөйләшеп утырдык. Болай сөйләгәндә, анда барып кайтуның бер куркынычы да юк шикелле тоеладыр инде. Ләкин, без килде дип, хәрби хәрәкәт туктап тормады. Без дә, үз гомеребезне куркыныч астына куюыбызны аңлап, Аллага тапшырып чыгып киттек, – дип сөйләде Алмаз Гыйматдинов.

Җыйган әйберләрен, бигрәк тә машинаны Раилнең үз кулына тапшырасы килгән аларның. Анда баруларын белгәч, ярдәм итәргә теләк белдерүчеләр яза, шалтырата башлаган.

– Кешеләрнең бердәмлеге, мәрхәмәтлелеге сокландыра. Бер дә таныш булмаганнар да әйберләр китерә башлады. Беркөнне бер апаң, шалтыратып: «Улым, сатарга дип сарымсак әзерләп куйган идем. Сез солдатлар янына барасыз икән, биреп җибәрим әле шуны? Башка берничек тә ярдәм итә алмыйм шул мин аларга», – ди. Сүзсез калдым. Чистайда яшәүче таныш егетләр дә бик тырыша, алар да махсус операциядә катнашучы якташларыбызга дип машина сатып алдылар, – ди Алмаз.

Ә солдат егетләргә килгәндә, берсе бер зарлану сүзе дә әйтмәде, ди әңгәмәдәшебез.

– Алар ил алдындагы бурычларын да, сайлаган һөнәрләренә карата җаваплылыкны да яхшы тоя. Яхшыга өмет, ышаныч та көчле аларда. Әле менә декабрьдә тагын барып кайтырга ниятлибез. Яңа ел җитә бит! Бәйрәм алдыннан күчтәнәчләр алып барып, үзенә күрә бер табын корып сөйләшеп утырырга иде. Шушы ниятебезне тормышка ашырырга насыйп булса иде, – ди Алмаз.

Монда Яңа ел кайгысы юк әле, дип зарланышканны уйлап, хәрбиләрдә бәйрәм кәефе бармы соң, дип кызыксындым.

– Соң, аларның да бәйрәм итәсе килә бит! Ә без монда алар өчен кайгырып, борчылып, кайтмаслар, дип, бәйрәм чараларыннан баш тартсак, егетләребез нишләр? Алай итеп, кәефләрен төшермик әле. Бу – минем фикер генә, билгеле. Ләкин сугыш вакытында да бәйрәмнәрдән баш тартмаганнар бит. Яхшыга өметләник! – диде Алмаз.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Татарстаннан хәрби операция зонасына тагын ике «УАЗ» машинасы җибәрелгән. Бу изге гамәл башында Түбән Кама районы җитәкчесе Рамил Муллинның «ВКонтакте»дагы шәхси сәхифәсенә Алсу Авзалова исемле ханымның транспорт белән ярдәм итүләрен сорап язган хаты тора. Хатны аңа мобилизациягә эләккән ире язарга куша. «Аларга транспорт бик кирәк, чөнки әллә ничәшәр чакрым ераклыкка кабель ташырга туры килә, авыр бит. Мин Рамил Хәмзовичның шәхси битенә мөрәҗәгать итәргә булдым һәм икенче көнне үк мәсьәләнең игътибарга алынуы турында җавап килде», – ди Алсу Авзалова үзе.
Машиналар сатып алу өчен акчаны, район башлыгы кушу белән, хәйриячеләр, эре предприятиеләр ярдәмендә тиз генә җыеп алганнар. Бер «УАЗ»ны – «Тимер» отрядына, икенчесен мобилизацияләнгән ир-егетләргә тапшырачаклар. «Бу – бөтен Түбән Камадан, илебез һәм егетләребез язмышына битараф булмаган барлык кешеләрдән җыелган ярдәм. Без егетләребезнең исән-сау кайтуларын гына телибез. Алга таба да аларны бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итәчәкбез», – диде Рамил Муллин.

Җыр калсын күңелдә

Моң белән озаталар. Мобилизацияләнгән егетләр өчен Казан читендәге танк полигонында һәм «Казан Экспо»да концерт узды. Патриотик җырлар һәм дәртле биюләр белән эстрада артистлары ир-егетләрнең күңелен күрергә тырышты.

Танк полигонында узган концертта ир-атларны үз чыгышлары белән Татарстанның атказанган артистлары Алинә Шәрипҗанова, Ләйсән Закирова, Марина Карпова һәм башка артистлар сөендерде. Урамда кышкы салкын булса да, Ватанны саклаучыларны бу гына туктатып калмады. Егетләр артистларны алкышларга күмде, аларга кушылып җырлады һәм биеде.

– Мондый концертларда беренче тапкыр гына чыгыш ясамыйм. Ир-егетләребезне куандырырга, рухларын күтәрергә, алар белән булырга тырышабыз. Бүген бу бик мөһим, дип уйлыйм. Алар безнең белән бергә җырлыйлар, бииләр, үзләрен игътибарсыз калдырмаганга сөенәләр. Беркайчан да бирешмичә, бары тик алга барып, егетләребезнең җиңеп кайтуларын телибез, – ди Алинә Шәрипҗанова.

Марина Карпованың икетуган энесе хәзер хәрби хәрәкәтләр зонасында икән. Җырчы хис-кичерешләре белән бүлеште.

– Энемнең исән-сау әйләнеп кайтуына, барысы да яхшы булачагына чын күңелдән ышанам. Мобилизация кагылмаган гаилә юктыр инде ул. Монда күз яшьләрен тыеп булмый, чөнки алар – кемнәрнеңдер уллары, абыйлары, ире. Һәр әни, һәр хатын-кыз якыннарын исән-сау каршыласын иде. Без күңелсезләнмибез, киләчәккә ышаныч белән карыйбыз, – ди Марина Карпова.

Мобилизацияләнгән егетләр дә артистларның чыгышына битараф калмады. Концерт 37 яшьлек Искәндәр Сабирҗановның күңеленә хуш килгән. Көн саен булса да ярый әле, ди ул.

– Мондый ярдәм безгә бик кирәк. Ул безгә көч һәм кыюлык бирә, кәефне күтәрә. Моңа кадәр дә, Чаллыдан килеп, концерт оештырганнар иде. Без моңа шат кына. Ул бит безнең истә кала. Исән-сау әйләнеп кайтсак, Алла боерса, тагын очрашырбыз әле. Ял көннәрендә гаиләм белән күрешеп торабыз. Мөмкинлек булса, үзем дә алар янына кайтып киләм, – ди ул.

«Казан Экспо»да концертны Татарстан дәүләт хоры башлап җибәрде. Эстрада артистлары башкарган җырларга егетләр кушылып җырлап утырсалар, оста баянчы Булат Хисмәтов уйнаган татарча бию көенә басып, дәррәү бии башладылар.

Татарстанның халык артисты Зәйнәб Фәрхетдинова җырлап бетергәч, ир-атларга җылы теләкләрен җиткерде:

– Сез барыгыз да – илебезнең һәм республикабызның чын патриотлары. Без сезнең белән горурланабыз. Исән-имин кайтырга язсын үзегезгә, – диде халык җырчысы.

Концерт барышында Теләче егете Алмаз Гыймадетдинов үзенең тәэсирләре белән уртаклашты. Ул күптән түгел 23 яшен тутырган.

– Китәр вакыт якынлаша инде, шуны көтәбез. Әти-әни белән аралашып торабыз. Борчылалар, билгеле, тик моны бик сиздерергә тырышмыйлар. Ә безнең кәефләр күтәренке. Мондый концертлар тагын да дәрт өсти. Үзебезгә уңышлар, сабырлык һәм җиңү белән кайтуны телим, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Спорт

rubin-kazan.ru

Быелга тәмам

Футбол буенча беренче лига командалары кышкы ялга китте. Соңгы ике очрашуны җиңү белән тәмамлаган «Рубин» турнир таблицасында өченче урынга урнашты. Язга кадәр командада үзгәрешләр көтәләр. Әмма нәрсәнең ничек буласы баш тренер вазыйфасына кемнең билгеләнәсенә бәйле.

Леонид Слуцкий киткәннән соң аның урынына вакытлыча билгеләнгән Юрий Уткульбаев җитәкчелегендә Казан командасы ике уенны да үз файдасына төгәлли алды. Беренчесендә Уфада җиңү яулаган «Рубин» елның соңгы очрашуында үз кырында «Нефтехимик»тан өстен чыкты. Башкала футболчылары ике очрашуда да икешәр туп кертте. Күп түгел, аның каравы команда уенында тотрыклылык һәм ышаныч сизелә. Яңа остаз уенчылар белән уртак тел табарга өлгергән. «Бу вакыт эчендә генә зур үзгәрешләр ясап булмый. Футболчыларга уен кырында үзләренең иң яхшы сыйфатларын күрсәтергә мөмкинлек бирдем», – диде Юрий Уткульбаев «Нефтехимик»ка каршы узган очрашудан соң.

Уткульбаевка үзен күрсәтү өчен ике матч бирделәр. Командасы ике матчта 6 очко алды. Аның эшендә бу көннәрдә Ирандагы сәфәрен тәмамлап, җылы Сочи якларына юл тотучы Корбан Бәрдыев алымнарын күрүчеләр дә бар. Команда сакта ышанычлы уйнарга, шул ук вакытта һөҗүмдә мөмкинлекне кулдан ычкындырмаска тырыша. Иң гаҗәбе, матч ахырында «Ак барс Арена»га җыелган тамашачы яңа остазның исемен әйтеп кычкыра башлады. Үз итеп. Казанда туып-үскән тренерны җанатарлар якын күрә. «Иң мөһиме, алар команда өчен борчыла. Эш бит Уткульбаевта да, Петров яки Сидоровта да түгел. Команда белән ни генә булса да, тамашачы аның өчен җан атарга тиеш. Иң мөһиме әнә шул. Яхшы уен була, начары да килеп чыга. Футболчылар да – кеше. Кәефе төшәргә, гаиләсендә берәр нәрсә килеп чыгарга мөмкин. Егетләрнең уйныйсы килә, командага җанатарларның ярдәме кирәк. Уенчылар иркенәеп китмәсен өчен тренерлар һәм клуб җитәкчеләре бар», – ди Юрий Уткульбаев.

Киләсе очрашуны «Рубин» 5 мартта уздырачак. Өч ай эчендә командада үзгәрешләр булмый калмас. Казанга Леонид Слуцкий чакырганга килгән, аның кулы астында чыгыш ясарга җыенган футболчылар да бар. Килү-китүчеләр баш тренер вазыйфасына кемнең билеләнәсенә дә бәйле булачак. Юрий Уткульбаев бу эштә калырга теләгәнен яшерми. «Мин «Рубин»да теләсә нинди вазыйфада эшләргә әзер. Бу – минем клуб, – ди ул. – Команда көрәшергә һәм зур бурычларны үтәргә әзер».

	Команда	уен	очко
1	Балтика	20	41
2	Алания	20	38
3	Рубин	20	37
4	Енисей	20	34
5	СКА-Хабаровск	20	33
6	Арсенал	20	32
7	КАМАЗ	20	31
8	Волгарь	20	30
9	Шинник	20	28
10	Нефтехимик	20	27
11	Динамо Мх	20	26
12	Родина	20	22
13	Акрон	20	22
14	Велес	20	20
15	Кубань	20	19
16	Уфа	20	18
17	Волга Ул	20	15
18	Краснодар-2	20	13

Белдерү

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющимся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в реестре СРО «0182», дата вступления 05.07.2013 г.), квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085, в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:082501:282, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, садоводческое некоммерческое товарищество «Акинское», участок 282, выполняются кадастровые работы по уточнению границ и площади земельного участка с кадастровым номером 16:16:082501:282.

Заказчиком кадастровых работ является Лексина М.Л. (тел.: +79656043700). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, 29 декабря 2022 г. в 10.30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с ежедневно с 9.00 до 17.00 часов с 1 декабря 2022 г. до 29 декабря 2022 г. по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ:

– 16:16:082501:268, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, садоводческое некоммерческое товарищество «Акинское», участок 268;

– 16:16:082501:446, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, садоводческое некоммерческое товарищество «Акинское», участок 281.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

«Киләчәк уеннары – 2024»

Башта – компьютерда, аннан – мәйданда. Казанда көрәшчеләр яңача көч сынашты. Юк-юк, сүз милли көрәш һәм анда кагыйдәләр үзгәреше турында бармый. Яңа төрле көрәш «Фиджитал уеннар» кысасында үтте. Катнашучылар башта компьютер уенында (Мортал Комбат) кем көчлерәк булуын расласа, аннан көрәшне мәйданга (октагон) күчерделәр. Узган еллардагы ярышка күзәтү ясарга тәкъдим итәбез.

Мәгълүм булганча, Казан «Фиджитал уеннар»ны 2024 елда узачак «Киләчәк уеннары» халыкара турнирына әзерлек кысасында оештырды. Ноябрь ярышлары төгәлләнде. 10–11 декабрь көннәрендә кабат уеннар көтелә. Анысында спортчылар фиджитал-хоккейда көч сынашачак. Ягъни башта виртуаль дөньяда алка суксалар, аннан осталыкларын бозда күрсәтәчәкләр.

Тамаша һәм кунаклар

«Фиджитал уеннар»ның фиджитал-көрәш ярышын карарга «йолдызлы» кунаклар да килгән иде. Әйтик, катнаш көрәш буенча дөнья чемпионы Петр Ян, спорт гимнастикасы буенча Олимпия чемпионы Никита Нагорный һәм блогер Алексей Столяров. Кунаклар да яшерми: Казан шаккатыра белә. Бу ярышлар да – шуның дәлиле.

«Фиджитал уеннар»ның якындагы чынбарлыгыбыз икәнен алар да яхшы аңлый. Әйтик, Петр Ян аны үз гаиләсендә дә куллана. Ничекме?

– Минем ике улым бар. Зурысына – 6 яшь. Балалар бакчасына йөри. Ул да, бүтән балалар кебек үк, телефон сорый, шуның белән уйный. Мин исә телефонны аңа 100 «отжимание» ясаганнан соң гына бирәм. Кушканны үтәгәч, ярты сәгать уйнап ала. Мин аның андый уеннар уйнавына каршы килә алмыйм, – диде ул.

Петр Ян сөйләгән тәрбия үрнәгенең уеннарга ни катышы бар инде, дип тәнкыйтьләргә ашыкмыйк. Фиджитал ярышларның асылын да бит санлы дөнья мөмкинлекләре һәм физик көч кушылмасы тәшкил итә.

Петр Ян Казандагы ярышларның инде киләчәк түгел, чынбарлык икәнен дәлилләргә тырышса, блогер Алексей Столяров оештыру дәрәҗәсенә тукталды. Мактау сүзләрен күп яудырды ул. Монысы белән бәхәсләшеп булмас: Татарстан һәм аның башкаласы төрле дәрәҗәдәге ярышларны оештырып, остарып бетте инде. Тарих өчен яңа булган «Фиджитал» дигәнен дә Казанга ышанып тапшырулары юкка түгелдер, димәк.

> Яшерен-батырын түгел, безне төрле дәрәҗәдәге чараларга гел дәшеп торалар. Бөтен җирдә бер үк төрле нәрсәләр. Казанда исә барысы да үзгә һәм бик югары дәрәҗәдә. Бу – чыннан да, киләчәк уеннары, – диде блогер.

Алгарак китеп, кунакларның спортчылар өчен чын күңелдән җан атып утыруларын да әйтик.

Петр Ян сүзләренчә, безгә замана технологияләренең тормышыбызда зур роль уйнавын танырга вакыт. «Йә заман белән бергә атлыйсың, йә артта каласың. Турнирга килгәндә, ярышка спортчылар да җентекләп сайланган, алар әзерлек буенча да бер тирәдә. Тамашачылар да уеннардан канәгатьтер», – диде Петр Ян.

gamesofuture.com

Дагыстан егетләре җиңүче булды.

Ярыш һәм җиңүчеләр

Фиджитал-көрәштә алты команда ярышты. Болар – Иран, Казахстан, Россия һәм Беларусь илләреннән килгән егетләр. Команда составында – ике кеше. Катнашучылар 700 мең сум күләмдә акчалата бүләк, чемпион исеме һәм кубок өчен көч сынашты.

Уенны күз алдыгызга китерү өчен, аны тасвирлап карыйк. Катнашучы егетләр (аларны алдан жирәбә белән сайладылар, моңа кадәр егетләр үлчәнү дә узды. – **Авт.**), октагонга чыгып, «Мортал Комбат» дигән компьютер уены уйнады. Виртуаль көрәштән соң, спортчылар мәйданга чыкты. Алар ММА (катнаш көрәш) төрендә көчләрен сынашты. Уенчыларның баллары кушыла барды. Шулай ук тамашачылар активлыгы да исәпкә алынды. Әйтик, «иң яхшы нокаут», «иң яхшы көрәшче», «иң креатив алым» кебек юнәлешләрдә халык мәхәббәтен яуларга мөмкинлек бирелде егетләргә.

Компьютерда ярышу – бер нәрсә. Ә мәйданда кан да чыга, катнашучылар да имгәнә. Хөкемдарларга да җиңел булмады: бер парның нәтиҗәләрен яңадан карап чыгарга туры килде.

Нәтиҗәдә Дагыстан егетләре Хәбиб Магомедов һәм Анзор Абжамов чын көрәштә дә, компьютер уеннарында да шаккатырды һәм җиңү яулады.

– «Мортал Комбат»та уйнау иң авыры булды, әллә ни тәҗрибәм юк иде. Әмма миңа ошады, – диде Анзор, җиңгәннән соң.

Хәбиб исә, җиңү өчен килмәдем, ди. «Тамаша, яңалык кызыксындырды. Әле катнашу-катнашмавым соңгы минутка кадәр билгеле түгел иде. Чөнки температурам күтәрелде. Шөкер, барысы да яхшы тәмамланды», – диде җиңүче.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ӨЧЕНЧЕ ЙОЛДЫЗ

«Яңа йолдыз» телевизион вокал проекты кабат яңа йолдызлар кабыза. «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә бәйгенең өченче сезоны гала-концерты узды. Быел татар эстрадасының «яңа йолдыз»ы кем булды? Тамашаны без дә күреп кайттык.

Талантлы яшьләрне тамашачыга күрсәтү, зур сәхнәгә күтәрү максатында үткәрелгән проектка быел 700дән артык гариза килгән. Конкурста Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче 18 яшьтән 35 яшькә кадәр булган һәр кеше катнаша алды. Гариза бирүчеләр арасыннан сайланган 50 кеше кастингта катнашып, шулардан 12 талантлы башкаручы сайлап алынды. Алар, ике командага бүленеп, бер ай дәвамында остазлары – Татарстанның халык артисты Зөфәр Хәйретдинов һәм Татарстанның атказанган артисты Артур Минһаҗев белән шөгыльләнделәр. Вокал, актерлык осталыгы һәм башка юнәлешләр буенча мастер-класслар үттеләр.

Концерт башланганчы, Зөфәр Хәйретдинов белән аралашып алдык.

– Остаз буларак миңа яшьләр белән эшләү җиңел булды, чөнки тәҗрибәм дә зур, тиешле белемем дә бар. Шулар белән уртаклашып, аларга үземнең белгәннәремне җиткерергә, киңәшләремне бирергә тырыштым. Яшьләр белән чын күңелдән, рәхәтләнеп эшләдек, – диде җырчы. – Хәзер конкурслар бик күп. Кайвакыт аларда «йолдыз» була алырлык башкаручылар да күренгәли. Монда алай ук димәс идем. Катнашучыларның составы тигез, бер-ике башка өстенрәк булганнары юк. Яхшы «бриллиант» тавыш әллә кайдан күренә ул. Сәхнә өчен җырга һәвәслек һәм тыш-кыяфәт тә мөһим, – диде җырчы.

«Барс Медиа»

Финалга барлыгы 6 катнашучы узды: Алия Габиева, Игорь Дмитриев, Алинә Газизова, Фәридә Ибраһимова, Диана Дәүләтшина һәм Инсаф Габделбәров. «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә узган гала-концертта финалга узган яшь башкаручылар татар эстрадасының популяр җырчылары Рәсим Низамов, Алинә Шәрипҗанова, Илгиз Шәйхразиев, Илнат Фәрхуллин, Алсу Әбелханова, Эльмира Кәлимуллина белән дуэт башкарды.

Икенче команданың остазы Артур Минһаҗев, мондый проектлар яшь башкаручыларны дөрес юлга бастыра, дигән фикердә:

– Бу – бик тә кирәкле проект. Хәзер яшь җырчылар бик күп, аларның зур сәхнәгә чыгасы, үзләрен күрсәтәселәре килә. Бүген репетициядә карап тордым да, Аллага шөкер, бергә очрашып, шөгыльләнгән вакытлар бушка гына үтмәгән, дип уйлап куйдым. Яшьләрнең җырларны профессиональ яктан дөрес итеп башкаруын, сәхнәдә үзләрен тотышларын күреп шатландым.

Сәхнәгә арзан алкышлар, кырын балкышлар эзләп чыгарга кирәкми. Жюри әгъзасы, Татарстанның халык язучысы Зөлфәт Хәким яшьләргә әнә шулай диде.

– Яшь җырчылар шуны бүгеннән аңлап эш итсен иде. Кеше фикеренә, әйткән сүзгә дә артык игътибар бирмәсеннәр иде. Көймә суда йөзеп барганда гына әйбәт бара. Эченә су тулса, бата. Кеше дә шулай. Кеше фикеренә колак салыгыз, әмма тискәре фикер ишетәсез икән, коелып төшмәгез. Синең эчке халәтең кеше фикеренә караганда кыйммәтрәк, – диде халык язучысы. – Монда үз максатына ирешергә омтылган, ихлас күңелдән иҗатка тартылган яшьләр җыелган. Тик нинди генә уңышларга ирешсәң дә, әллә нинди талантлы кеше булсаң да, үзеңнең кем икәнеңне, каян чыкканыңны, кемнәр ярдәм иткәнне, туганнарыңны онытмаска кирәк. Без бер үзебез генә бу дөньяда беркем дә түгел.

Жюри әгъзасы, Татарстанның атказанган артисты Данир Сабиров үзе дә балачакта һәм үсмер вакытында җыр бәйгеләрендә катнашып йөрүен искә алды.

– Миңа анда бер урын бирмичә, гел «Тамашачы мәхәббәте призы» дипломын тоттырып кайтарып җибәрәләр иде. «Иң»нәрдән «иң»ен сайлау кыен, тик җиңүче берәү генә була. Шунысы да бар: монда җиңү әле – «йолдыз» булу дигән сүз түгел. Иң мөһиме – тамашачының күңелен яулау, – ди артист.

«Яңа йолдыз» проектының өченче сезоны җиңүчесе булып Мамадыш кызы Фәридә Ибраһимова табылды. Ул «Барс Рекордс» продюсерлык үзәге белән килешү төзү, җырларын профессиональ яздыру, клип төшерү һәм аны «ТМТВ» телеканалына ротациягә бирү мөмкинлегенә ия булды. Шулай ук яшь җырчы эстраданың иң затлы, матур вакыйгасы – 20 елдан артык тарихы булган «Татар җыры – 2022» фестивалендә катнашачак.

Фәридә өчен җиңү чын мәгънәсендә көтелмәгән һәм бик шатлыклы вакыйга булды.

– Нәрсә булганын әле аңлап бетерә алмыйм. Мондый дәрәҗәгә җитү – бик зур шатлык. Остазларга барлык киңәшләре өчен, дусларыма, туганнарыма, яраткан тамашачыма минем белән булулары өчен бик зур рәхмәт! – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6697 данә
Гомуми тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 376

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+